ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН
2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”
МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ

| «КАРАЛДЫ» | «КИЛЕШЕНДЕ» | «РАСЛАНДЫ» |
|---|---|---|
| Методик берләшмә җитәкчесе<br>__________И.Х.Замалиева<br>МБ утырышы беркетмәсе<br>№1 «25» август 2016 ел | Директор урынбасары<br>_________Л.Р.Ягудина<br><br>«27» август 2016 ел | Мәктәп директоры<br>___________Л.Н.Липлянина<br>Педагогик совет беркетмәсе<br>**233** нче номерлы боерык белән гамәлгә кертелде.<br>31 нче август 2016 ел |

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Хәбибрахманова Халисә Харис кызы
3 «Б» сыйныфы өчен татар теленнән
эш программасы

Педагогик киңәшмә
Утырышында каралды.
Беркетмә №1
31 август 2016 ел

2016 - 2017

## I. Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

Сыйныф: 3 “Б”
Укытучы: Хәбибрахманова Х.Х.
Уку планы буенча татар теленнән: 102 сәг.
Атнага: 3 сәг.
Контроль эшләр: 9
Сүзлек диктанты: 2
Күчереп язу: 2
Дәреслек. Татар теле. Күңелле татар теле. Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен)
Төзүчеләре:Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина
Татар теле китабы. Ике кисәктән тора. Казан. «Татармультфильм» нәшрияты, 2013 ел

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2016-2017 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел).

### Татар теленә өйрәтүнең предмет нәтиҗәләре.

**Сөйләшү** Диалогик сөйләм. 3 нче сыйныфта дәрес вакытының 60-70%ын сөйләшүгә өйрәнү ала. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- сайланган эчтәлек аша әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

Монологик сөйләм. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеклеген сүрәтләп сөйли белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү.

**Ишетеп аңлау (аудирование)**

Аралашу өчен төп шартларның берсе – әңгәмәдәләрнең бер-берсенең сөйләмен аңлавы. 2 нче сыйныфта ишетеп аңларга өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:

- нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда кулана белергә өйрәтү;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәтү;
- ишетү хәтеренең күләмен үстерү.

**Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:**

- хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;
- дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
- укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
- укыганда сүзлекләр куллана белү.

Дәреслектә уку техникасын үстерүгә ярдәм итә торган рифмовкалар, җырлар, рифмалаштырылган әкиятләр бирелде. Үзләштерү дәрәҗәсенә карап, укытучы аларны арттыра яки киметә ала.

**Язу.** Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбендәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;
- дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;
- бәйрәмнәр белән котлау язу.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр**

1)татар телен өйрәнүнең әһәмиятен белү;
2)татар теленең алфавитын яттан белү, авазларны дөрес әйтә белү һәм хәрефләрне дөрес яза белү;
3)бирелгән текстларны дөрес укый һәм яза белү;
4)әйтелеше һәм язылышы арасында аерма булган сүзләрне яза белү;
5)сүзләрне иҗекләргә бүлә белү;
6)сүз басымын дөрес куеп, сүзләрне әйтә белү;
7)хикәя,сорау,боеру җөмләләрне дөрес интонация белән әйтә белү;
9)актив үзләштерелгән исемнәрне сан, килеш,тартым белән төрләндереп, телдән һәм язма сөйләмдә куллана белү;
10)татар телендә исемнәргә кем? нәрсә? сорауларын кую үзенчәлеген белү;
11)татар телендә сыйфат һәм исем, сан һәм исем төзелмәләренең кулланылыш үзенчәлекләрен белү;
12)фигыльнең өйрәнелгән заман формаларын сөйләмдә куллануга ирешү;
13)татар һәм рус телләренең уртак һәм аермалы якларын белеп,сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес оештыра белү;
14)ана теле тәэсирендә барлыкка килгән әйтелеш һәм сөйләм хаталарын төзәтә белү;
15) актив үзләштерелгән җөмлә калыпларын тыңлап яки укып аңлый белү, татар җөмләсендә сүз тәртибе кагыйдәләрен истә тотып, аларны сөйләмдә куллануга ирешү;
16)сорау һәм җавап репликаларын дөрес кулланып, әңгәмә кора алу;
17)татар сөйләм этикетына хас булган танышу, исәнләшү, сайбуллашу, рәхмәт әйтү, гафу үтенү һәм башка калыпларны урынлы куллана алу;
18)тасвирлау яки хикәяләү төрендәге бәйләнешле текст төзи белү;
19)телдән һәм язмача диалогик яки монологик формада аралаша белү;
20)бәйләнешле текстларны сәнгатьле итеп һәм эчтәлеген аңлап укый алу;
21) тиешле күләмдә татар сүзләрен яттан белү.

**Метапредмет нәтиҗәләргә ирешү:**

- Аңлап укый белү
- Рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү
- Үрнәк буенча эшли белү
- Уку хезмәтенә бәя бирә белү
- Аралаша белү сәләтен үстерү

- Парларда һәм күмәк эшли белү

## II. Укыту предметының эчтәлеге

**Белем бәйрәме** ( Беренче сентябрь – белем бәйрәме. Төсләр. Без диктант язабыз. Без дәрестә. Мин билге алам. Без китапханәгә йөрибез.

**Көндәлек режим**. Минем көндәлек режимым.

**Ашханәдә** Без ашханәдә ашыйбыз. Ми нем яраткан ашларым. Безгә кунаклар килә. Без табын әзерлибез.

**Без әти-әниләргә булышабыз.** Минем әти – әнием кем булып эшли? Без өйдә булышабыз. Без табын әзерлибез.

**Туган якка кыш килде.** Яңа ел бәйрәме. Һава торышы. Кышкы уеннар. Каникулда.

**Шәһәрдә һәм авылда** Татарстан – минем туган ягым. Татарстанда яшәүче милләтләр. Татарстан шәһәрләре. Без шәһәргә барабыз. Безнең авыл.

**Әдәпле булыйк**.Әдәпле сөйләшү. Телефоннан әдәпле сөйләшү. Туган көнгә чакыру. Табын янында. Без бүләкләр бирәбез.

**Кечкенә дусларыбыз** Дүрт аяклы дусларны сурәтләү, аларны карау. Минем яраткан песием.

**Күңелле җәй** Без җәйне яратабыз. Ел фасыллары билгеләре. Җәй җитә. Без җиләккә барабыз. Безнең бакча. Җәйге ял. Сабантуй – зур бәйрәм.

**Грамматик минимум**

1. Исем – сүз төркеме белән таныштыру.
2. Исемнең иялек килеше белән таныштыру.
3. Чы/-че - исем ясагыч кушымчалары белән таныштыру.
4. Сыйфат – сүз төркеме белән таныштыру.
5. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар белән танышу.
6. Синоним һәм антоним сыйфатларны сөйләмдә куллану.
7. 21дән 100 кадәр саннарны сөйләмдә куллану.
8. Аннан соң рәвеше һәм һәр, һәркем, барлык, алмашлыклары белән таныштыру.
9. Фигыль – сүз төркеме, аның хәзерге һәм үткән заман формалары белән таныштыру.
10. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта күплектә 1,2,3 зат формалары белән таныштыру.
11. –гына/-генә, -кына/-кенә кисәкчәләре белән таныштыру.
12. Янында, алдында, артында, турында бәйлек сүзләрен сөйләмдә куллану.
13. Ләкин, чөнки, шуңа күрә теркәгечле җөмләләрне сөйләмдә куллану.
14. Казан шәһәре, киемнәр кибете – төзелмәләре белән таныштыру.
15. Сәгать ничә? Сәгать ничәдә? сорауларын һәм аңа җавапларны сөйләмдә куллана белү. **Орфографик и орфоэпик минимум.**

1. Өйрәнелгән лексик берәмлекләрне орфоэпия нормаларына туры китереп әйтүне ныгыту. 2. Алынма сүзләрнең дөрес әйтелешен саклап, сөйләмдә кулланырга күнектерү.
3. Укучыларның язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерү эшен дәвам итү.
4. Ике бертөрле тартык янәшә килгән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу күнекмәләрен булдыру(китте, кайтты).
5. Янәшә килгән ике бертөрле тартык булган сүзләрне икеләтеп әйтергә өйрәтү.
6. я, ю, е хәрефләре, алар белдергән авазларның әйтелешен һәм язылышын истә калдыруны булдыру.
7. О, ө хәрефләренең беренче иҗектә генә язылуы.

**III.Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру.**

| № | Дәрес темасы | Эшчәнлек төре | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Беренче сентябрь - белем бәйрәме | Сәнгатьле итеп сөйләү, уку. | 2.09 |
| 2 | Кем? кемне? кемгә? сораулары һәм аларга җавап | Тәрҗемә итү, текстка таянып сөйләү. | 5.09 |
| 3 | Кая? кайда? кайдан? сорулары һәм аларга җавап | Тәрҗемә итү, текстка таянып сөйләү, сорауларга җавап бирү. | 7.09 |
| 4 | Кая? кайда? кайдан? сорулары һәм аларга җавап | Диалог төзү. | 9.09 |
| 5 | **Кереш контроль тест**.<br>- мы/-ме сорау кисәкчәсе | Контроль тест башкару. | 12.09 |
| 6 | Хаталар өстендә эш. Мин, син, ул зат алмашлыгының юнәлеш килеш форма-сы | Хаталар өстендә эш эшләү. | 14.09 |
| 7 | Мин, син, ул зат алмашлыгының юнәлеш килеш формасы | Диалог уку, парларда уйнау. | 16.09 |
| 8 | 1-10 га кадәр саннар | Уку, тәрҗемә итү. | 19.09 |
| 9 | Төсләр | Диалог төзү. | 21.09 |
| 10 | Исемнең күплек сан кушымчасы | Тәрҗемә итү, текстны сәнгатьле уку. | 23.09 |
| 11 | Кая? кайда? кайдан? сорулары һәм аларга җавап | Тәрҗемә итү, диалог төзү. | 26.09 |
| 12 | Исем сүз төркеме | Диалог төзү. | 28.09 |
| 13 | Исемнәрнең I зат берлек санда тар тым белән төрләнүе | Диалог төзү. | 30.09 |
| 14 | Фигыльнең башлангыч формасы | Сәнгатьле итеп уку, тәрҗемә итү. | 3.10 |
| 15 | Хәзерге заман,үткән  заман хикәя фигыльнең зат- санда төрләнеше | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 5.10 |
| 16 | Без диктант язабыз<br>Сүзлек диктанты<br>“Белем бәйрәме” | Диалог уку, парларда уйнау. | 7.10 |
| 17 | Хаталар өстендә эш. Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 10.10 |
| 18 | Чөнки, ләкин теркәгечләре | Диалог төзү. | 12.10 |
| 19 | Чөнки, ләкин теркәгечләре | Тәрҗемә итү, текстны сәнгатьле уку. | 14.10 |
| 20 | Сингармонизм<br>законы. | Уку, тәрҗемә итү. | 17.10 |
| 21 | **Контроль эш №1. Тема: Белем бәйрәме** | Тест биремнәрен үтәү. | 19.10 |
| 22 | Хаталар өстендә эш<br>Сингармонизм<br>законы. | Хаталар өстендә эшләү. | 21.10 |
| 23 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең берлек санда ю к л ы к   формасында | Диалог төзү. | 24.10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | зат-сан белән төрләнеше. | | |
| 24 | Ярдәм ит әле, ярдәм итегез әле төзелмәләре. | Сәнгатьле итеп уку, тәрҗемә итү. | 26.10 |
| 25 | Янында бәйлек сүзе. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 28.10 |
| 26 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең күплек санда юклык формасында зат-сан белән төрләнеше. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 7.11 |
| 27 | Саный сүзенең зат-сан белән төрләнеше. | Грамматик күнегүләр эшләү. | 9.11 |
| 28 | Дистә саннары. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 11.11 |
| 29 | Тема буенча лексик, грамматик материалын кабатлау | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 14.11 |
| 30 | Сәгать ничә? | Үрнәк буенча диалог төзү. | 16.11 |
| 31 | Сәгать ничәдә? | Грамматик күнегүләр эшләү. | 18.11 |
| 32 | Бу эшләрне мин кайчан эшлим? | Дәреслек белән эш. | 21.11 |
| 33 | **Тест : Көндәлек режимы** | Контроль эш башкару. | 23.11 |
| 34 | Хаталар өстендә эш. Боерык фигыль формасы. | Хаталар өстендә эш эшләү. | 25.11 |
| 35 | Исемнең төшем килеше. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 28.11 |
| 36 | Исемнең төшем килеше. **Күчереп язу** «Без урамда уйныйбыз» | **Күчереп язу** | 30.11 |
| 37 | Хаталар өстендә эш. Янында бәйлек сүзе | Хаталар өстендә эш эшләү. | 2.12 |
| 38 | Исемнәрнең юнәлеш, урын-вакыт, чыгыш килешендә төрләнүе. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 5.12 |
| 39 | Нәрсә ашыйбыз, нәрсә эчәбез? | Үрнәк буенча диалог төзү. | 7.12 |
| 40 | **Контроль эш №2** Тема: «Ашханәдә” | Контроль эш башкару. | 9.12 |
| 41 | Хаталар өстендә эш. Тема буенча лексик, грамматик материалын кабатлау | Хаталар өстендә эш эшләү. | 12.12 |
| 42 | Аның китабы, аның әнисе - төзелмәләре. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 14.12 |
| 43 | Сатучы булып эшли - төзелмәсе. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 16.12 |
| 44 | **Сүзлек диктанты** -чы/-чы сүз ясагыч кушымчасы. | Хаталар өстендә эш эшләү эшләү. | 19.12 |
| 45 | Хаталар өстендә эш. Үз алмаш-лыгының тартым белән төрләнеше | Таблица белән эшләү. | 21.12 |
| 46 | “Без әти-әниләргә булышабыз” | Грамматик күнегүләр | 23.12 |
| 47 | Уң як, сул як төзелмәсе | Лексик берәмлекләрне | 9.01 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | үзләштерү. | |
| 48 | Тема буенча лексик, грамматик материалын кабатлау | Грамматик күнегүләр эшләү. | 11.01 |
| 49 | Исемнең иялек килеше белән таныштыру | Лексик берәмлекләрне үзләштерү | 13.01 |
| 50 | я, ю, е хәрефләре, алар белдергән авазларның әйтелешен һәм язылышын истә калдыруны булдыру | Лексик берәмлекләрне үзләштерү | 16.01 |
| 51 | Чыршы бәйрәме. Ничә? Ничәнче? сораулары. | Диалог төзү. | 18.01 |
| 52 | Синоним һәм антоним сыйфатларны сөйләмдә куллану | Дәреслек белән эш, диалог төзү. | 20.01 |
| 53 | 21дән 100 кадәр саннарны сөйләмдә куллану | Лексик берәмлекләрне үзләштерү, грамматик күнегүләр эшләү. | 23.01 |
| 54 | Кыш айлары, кыш билгеләре | Рәсем буенча хикәя төзү. | 25.01 |
| 55 | Сыйфат сүз төркеме | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 27.01 |
| 56 | О, ө хәрефләренең беренче иҗектә генә язылуы | Грамматик күнегүләр эшләү | 30.01 |
| 57 | Хаталар өстендә эш. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта күплектә 1,2,3 зат формалары белән таныштыру | Таблица белән эшләү. | 1.02 |
| 58 | Спорт төрләре | Сорауларга җавап бирү. | 3.02 |
| 59 | Хәзерге заман, үткән заман хикәя фигыль | Эчтәлек хаталарын табу. | 6.02 |
| 60 | Нишләмәде? соравы | Сорау алмашлыкларын гамәли куллану. | 8.02 |
| 61 | **Тест "Туган якка кыш килде"** | **Тест башкару** | 10.02 |
| 62 | Хаталар өстендә эш. Тема буенча лексик, грамматик материалын кабатлау | Хаталар өстендә эш эшләү | 13.02 |
| 63 | Татарстан - минем туган ягым. | Хикәягә исем бирү.Сорауларга җавап бирү. | 15.02 |
| 64 | Татарстан - минем туган ягым. | Үзеңнең шәһәрең турында җөмләләр төзү. | 17.02 |
| 65 | Татарстан шәһәрләре. | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 20.02 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 66 | Без н и н д и транспортта барабыз? | Диалогларны рольләргә бүлеп уку. | 22.02 |
| 67 | Казан шәһәре, кибете – төзелмәләре белән таныштыру | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 24.02 |
| 68 | Без шәһәрдә яшибез. | Кушымчаларны дөрес куллану. | 27.02 |
| 69 | Нинди транспортта барабыз? | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 1.03 |
| 70 | Нинди йортта яшибез? | Текст буенча сораулар бирү. | 3.03 |
| 71 | Сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе. | Сәнгатьле уку. | 6.03 |
| 72 | Без шәһәргә барабыз | Грамматик күнегүләр эшләү. | 8.03 |
| 73 | **Контроль эш№3. Тема:** “Шәһәрдә һәм авылда” | **Контроль эш эшләү.** | 10.03 |
| 74 | Хаталар өстендә эш.<br><br>Аннан соң рәвеше һәм һәр, һәркем, барлык, алмашлыклары белән таныштыру | Хаталар өстендә эш эшләү.сораулар төзү. | 13.03 |
| 75 | Мин авылда яшим. | Сәнгатьле уку. | 15.03 |
| 76 | Янында, алдында, артында, турында бәйлек сүзләре | Диалогларны рольләргә бүлеп уку. | 17.03 |
| 77 | Әдәпле сүзләр. | Тулы җаваплар бирү, | 29.03 |
| 78 | –гына/-генә, -кына/-кенә кисәкчәләре белән таныштыру<br>**Күчереп язу** «Трамвайда» | **Күчереп язу** | 31.03 |
| 79 | Хаталар өстендә эш.<br>Туган көнгә бүләк бирәм. | Хаталар өстендә эш эшләү. | 3.04 |
| 80 | Дусларны каршылыйм. | Сорау алмашлыкларын гамәли куллану. | 5.04 |
| 81 | Табын янында | Сорауларга җавап бирү. | 7.04 |
| 82 | Әниләр бәйрәме | Хикәягә исем бирү. | 10.04 |
| 83 | Без бүләкләр бирәбез | Сорауларга җавап бирү. | 12.04 |
| 84 | Кем? Кемгә? сораулары | Диалог төзү. | 14.04 |
| 85 | Ике бертөрле тартык янәшә килгән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 17.04 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | күнекмәләрен булдыру(китте, кайтты) | | |
| 86 | Янәшә килгән ике бертөрле тартык булган сүзләрне икеләтеп әйтергә өйрәтү | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 19.04 |
| 87 | Киемнәр кибете – төзелмәләре белән таныштыру | Текст буенча сораулар бирү. | 21.04 |
| 88 | **Тест "Әдәпле булыйк"** | **Тест башкару** | 24.04 |
| 89 | Хаталар өстендә эш . Алынма сүзләрнең дөрес әйтелешен саклап, сөйләмдә кулланырга күнектерү | Хаталар өстендә эш эшләү. | 26.04 |
| 90 | Көн саен төзелмәсе. | Текст буенча сораулар бирү. | 28.04 |
| 91 | Ул алмашлыгының килешләр белән төрләнеше. | Сәнгатьле уку. | 1.05 |
| 92 | Минем песием | Сәнгатьле уку. | 3.05 |
| 93 | Сыйфатның артыклык һәм чагыштыру дәрәҗәләре | Диалогларны рольләргә бүлеп уку. | 5.05 |
| 94 | Кабатлау дәресе | Кушымчаларны дөрес куллану | 8.05 |
| 95 | **Тест: "Кечкенә дусларыбыз"** | **Тест башкару** | 10.05 |
| 96 | Хаталар өстендә эш.<br>Без җәйне яратабыз. | Хаталар өстендә эш эшләү. | 12.05 |
| 97 | Өйрәнелгән лексик берәмлекләрне орфоэпия нормаларына туры китереп әйтүне ныгыту | Диалог уку, парларда уйнау. | 15.05 |
| 98 | Капма-каршы мәгънәдәге сүзтезмәләр. | Уку, тәрҗемә итү. | 17.05 |
| 99 | **Еллык контроль эше.** | **Контроль эш эшләү.** | 19.05 |
| 100 | Хаталар өстендә эш. Җәйге ял. | Хаталар өстендә эш эшләү. | 22.05 |
| 101 | Йомгаклап кабатлау дәресе | Тәрҗемә итү, диалог төзү. | 24.05 |
| 102 | Йомгаклап кабатлау дәресе | Диалог төзү. | 25.05 |

Пронумеровано прошнуровано
И скреплено печатью
10 / десять листов
Учитель татарского языка и
Литературы Хабибрахманова Х.Х.